# ЯНЫМДА СИН БУЛСАҢ

*И.БАЯЗИТОВ көе*
*Р.ШӘМСЕТДИН сүзләре*

Болытка әйләнеп, артыңнан йөгердем,
Теләсәң учыңда кар булып эрермен.

*КУШЫМТА:*
Кар булсам карармам,
Боз булсам бозылмам,
Мин мәңге картаймам,
Янымда син булсаң.

Эрермен, әмма син җанымны аңласаң,
Боз булып туңармын, янымда булмасаң.

*КУШЫМТА*

Калдырма боз итеп, куңелең кояш бит,
Син булсаң янымда көннәрем аяз бит.

*КУШЫМТА*